# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«31» июль 2019 ел　　　　Борды авылы　　　　№ 14

Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннарны билгеләү турында

Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 маддәсе 8 өлеше һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» 2019 елның 10 июлендәге 67/516 санлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Борды авылы, Үзәк ур., 59А й., «Виктория» кибете;
- Борды авылы, Үзәк ур., 59 й., «Сельмаг» кибете;
- Борды авылы, Үзәк ур., 85А й., «Хабиб» кибет-кафе;
- Борды авылы, Үзәк ур., 102А й., тукталыш павильоны;
- Жэйлэу авылы, Кыр ур., 1 й., «Виктория» кибете;
- Жэйлэу авылы, Үзәк ур., Фермер ур., 1 й., ООО «Усадьба Касакина" терлекчелек комплексы
- Бордыбаш авылы, Үзәк ур., 17А й., «Виктория» кибете;
- Бордыбаш авылы, Тау осте ур., 22 й., ООО «Сельспецстрой»;
- Бордыбаш авылы, тукталыш павильоны;
- Бордыбаш авылы, «Закиров А.Н.» КФХ комплексы.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Борды авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе　　　　Р.Н.Абдульманова

Исполнительный комитет БУРДИНСКОГО сельского поселения
ИНН 1639032248